ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында» 2019 елның 11 июлендәге 2983-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктның 6 пунктчасында «хокукый культура» сүзләреннән соң «һәм юридик грамоталылык» сүзләрен өстәргә;

2) 6 пунктның 2 пунктчасында «гомумроссия яшьләр» сүзләреннән соң «һәм балалар» сүзләрен өстәргә;

3) 8 пунктта «30 яшькә кадәр» сүзләрен «30 яшькә кадәр (30 яшьне дә кертеп)» сүзләренә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ – $9^2$ пунктлар өстәргә:

«$9^1$. Яшьләр парламенты әгъзасы Дәүләт Советында фракциясе булган партия вәкиле (алга таба – партия вәкиле) булырга мөмкин. Партия вәкиле Дәүләт Советына сайлауларда тиешле партиядән кандидатларның республика исемлеге составына кергән, Яшьләр парламенты составына кертелгән көнгә 30 яшькә кадәр (30 яшьне дә кертеп) булган Россия Федерациясе гражданы булырга мөмкин. Партияләр вәкилләрен Яшьләр парламенты составына кертү конкурстан тыш гамәлгә ашырыла.

$9^2$. Яшьләр парламенты составына партия вәкилен кертү партия вәкиленең шәхси гаризасы һәм Дәүләт Советындагы тиешле фракциянең

документлар белән рәсмиләштерелгән карары нигезендә Яшьләр парламенты Советы тарафыннан башкарыла.»;

5) 10 пунктта «һәм Дәүләт Советы депутатлары саны» сүзләрен «Дәүләт Советы депутатлары һәм партия вәкилләре саны» сүзләренә алмаштырырга;

6) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә үз-үзен күрсәтү юлы белән үз кандидатурасын күрсәткән Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда тәмамланган очракта тиешле исемлектәге иң күп санда тавыш җыйган чираттагы кандидат Яшьләр парламенты Советы карары нигезендә Яшьләр парламенты әгъзасы була. Әлеге карар Яшьләр парламенты Советы тарафыннан 10 көн эчендә кабул ителә.»;

7) түбәндәге эчтәлекле $11^1 – 11^5$ пунктлар өстәргә:

«$11^1$. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яшьләре арасыннан яисә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләреннән, Татарстан Республикасында гомумроссия яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре бүлекчәләреннән, устав максатлары яшьләрнең үсеше һәм үз-үзләрен табу өчен шартлар тудырудан һәм аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклаудан гыйбарәт булган республика иҗтимагый һәм коммерциячел булмаган оешмаларыннан, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Дәүләт Советында вәкилләре булган сәяси партияләрдән булган Яшьләр парламенты әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның кандидатурасын күрсәткән берләшмә, оешма йә аның кандидатурасын күрсәткән муниципаль берәмлекнең яшьләр палатасы (парламенты), әлеге Нигезләмә нигезендә вәкаләт бирелгән башка орган җиде көн эчендә яңа кандидатура буенча Яшьләр парламенты Советына тәкъдим кертергә мөмкин, ул әлеге кандидатураны Яшьләр парламенты составына кабул итү турында 10 көн эчендә карар кабул итә.

$11^2$. Югарыда аталган оешмалардан җиде көн эчендә яңа кандидатура турында тәкъдим кермәгән очракта, тиешле исемлектәге иң күп санда тавыш җыйган чираттагы кандидат Яшьләр парламенты әгъзасы була.

$11^3$. Әлеге Нигезләмәнең 11 һәм $11^2$ пунктларында күрсәтелгән исемлекләрдә иң күп санда тавыш җыйган башка кандидатлар булмаган очракта, Яшьләр парламенты әгъзалары әлеге Нигезләмә нигезендә конкурс уздыру юлы белән сайлап куела.

$11^4$. Конкурс нәтиҗәләре буенча Яшьләр парламенты әгъзаларының саны әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән санга туры килмәсә, Яшьләр парламентының тиешле категория буенча саны җитми торган әгъзаларын сайлау әлеге Нигезләмә нигезендә конкурс үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

$11^5$. Яшьләр парламенты регламентында каралган очракларда Яшьләр парламенты әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»;

8) 12 пунктта «, чакырылганнар исемлеген һәм алып бару тәртибен билгели» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Яшьләр парламенты әгъзалары беренче утырышта ачык тавыш бирү юлы белән Яшьләр парламенты әгъзалары арасыннан рәис, рәис урынбасарларын, җаваплы секретарь сайлап куя, Яшьләр парламенты Советының санлы составын билгели һәм аның әгъзаларын сайлап куя, Яшьләр парламенты комиссияләрен төзи һәм аларның рәисләрен сайлап куя. Яшьләр парламенты рәисенә кандидатлар үзләренең эшчәнлек программалары белән чыгыш ясарга тиеш.

Яшьләр парламенты рәисе урынбасарларының саны Яшьләр парламенты рәисе тәкъдиме белән Яшьләр парламенты тарафыннан билгеләнә.»;

10) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Яшьләр парламенты карарын Яшьләр парламентының сайлап куелган әгъзалары санынннан күбрәге, шулай ук аның составына кертелгән Дәүләт Советы депутатлары, партияләр әгъзалары хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.»;

11) түбәндәге эчтәлекле 24 пункт өстәргә:

«24. Яшьләр парламенты әгъзаларына, Дәүләт Советы Рәисе раслаган нигезләмәгә таянып, таныклык бирелә.»;

12) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентын төзү буенча конкурс турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 32 пункт өстәргә:

«Соңгы вакант урынга тиешле исемлектә тигез санда тавыш җыйган берничә кандидат дәгъва кылган очракта, Яшьләр парламенты составына кертеләчәк кандидатура буенча карар Комитет тарафыннан конкурс процедуралары кысаларында үткәрелгән чаралар нәтиҗәсен истә тотып кабул ителә.».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 24 декабре
№ 242-VI ДС